| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br><br>ул. Молодежная, д.68, д.Нижние Шаши, 422008<br>Тел.: (8-84369) 36-0-38; факс: 36-0-38 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КҮҢГӘР АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br><br>Молодежная урамы., 68 нче йорт, Түбән Шашы авылы, 422008<br>Тел.: (8-84369) 36-0-38; факс: 36-0-38 |
| --- | --- |

“17” август 2022 ел. № 18

# КАРАР

Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Күңгәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында " 2020 елның 25 мартындагы 6 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 нче номерлы " Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында” гы карары, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" гы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән ) нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 25 мартындагы 6 нчы номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Күңгәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә” түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорда нисбәте белән характерлана”;

1.2. 12 пунктның 2 абзацында "дәүләт (муниципаль) программаларының структур элементлары турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 3 пунктта "муниципаль программаларның структур элементлары" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Сибгатуллин Д.Р.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУНГЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ · ИНН 1610002378